СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.06.2021 Әгерҗе шәһәре № 10-4

Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча Әгерҗе муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру турында

Әгерҗе муниципаль районы җирлекләренең “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында” карарларын карап һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча җирлекләрнең вәкаләтләрен кабул итәргә һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетына кабул ителгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны йөкләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетына Әгерҗе муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән тиешле килешүләр төзергә һәм аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе

А.Р. Вәлиев